| | |
|---|---|
| ГЛАВА ЧУКМАРЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧУКМАРЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2019 ел, 1 ноябрь Чукмарлы авылы № 5

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге Нарат – Асты авылы гражданнарының үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1.Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Нарат – Асты авылы гражданнары җыенын Нарат - Асты авылы медпункт бинасында 2019 елның 14 ноябренә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: I нче группа инвалидлар, ялгыз өлкән кешеләр, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан кала, Чукмарлы авыл җирлегендә теркәлгән 18 яше тулган һәр гражданга 2020 елда үзара салымны 200 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга Сез ризамы:

- Нарат Асты авылы урамына вак таш җәю (таш ташу);
- Нарат - Асты авылындагы юлларны кыш көне кардан чистарту;
- Нарат-Асты авылында мәдәни чаралар уздыру өчен бүләкләр алу (Сабантуй, өлкәннәр көне, 9 Май)

ӘЙЕ ЮК?».

3. Гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны Чукмарлы авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.

4. Әлеге карарны «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә, Нарат - Асты авылы территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

5. Әлеге карар игълан ителгэн көненнән үз көченә керә.

Чукмарлы авыл җирлеге башлыгы: И.Х.Хадиуллин